СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 2А, д.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 2А йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)5-07-35, факс (843665-07-35). E-mail: Sat.Ars@tatar.ru


**Урта Аты авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**«18» ноябрь 2019 ел** **№ 112**

**Урта Аты авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 48 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенең 31 бүлеге, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Аты авыл җирлеге Уставы нигезендә Урта Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Урта Аты авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 85 номерлы «Җир салымы турында» карарына (Урта Аты авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 августындагы 101 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның 3.1.1 пунктындагы беренче абзацында «автомобиль юллары» сүзләреннән соң «, әлеге карарның 2 пунктындагы 2.1 пунктчасында күрсәтелгәннәрдән тыш, " сүзләрен өстәргә»;

2) 4 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасының гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән бер ай үткәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Батталова

СОВЕТ СРЕДНЕАТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ